**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Бграж авыл җирлегенең Сарсаз-Баграж торак пунктында**
**2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2022 елның 16 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең Сарсаз-Баграж торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Баграж авыл җирлеге Сарсаз-Баграж торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- авыл эчендәге күперне ремонтлау һәм төзекләндерүгә;
- чишмә территориясен төзекләндерүгә;
- урам яктырткычларын ремонтлауга;
- зиратны төзекләндерүгә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» уранаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) 7 көн дәвамында (Баграж авыл җирлеге Уставның 69 п.5 статься) кабул ителгән көннән.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Баграж авыл җирлеге башлыгы П.Н. Минеев